**Промежуточная аттестация**

**Спецификация:**

Предмет: родной язык (татарский базовый), 11 класс

**Условия проведения процедуры промежуточной аттестации:**

Работа проводится в классе, задания выполняются на бланках (листы со штампом школы)

**Время выполнения:**

На выполнение всей работы отводится 45 минут.

**Назначение работы**:

Определить уровень овладения предметных результатов и коммуникативных УУД у учащихся 11 класса по итогам усвоения программы по предмету «Родной (татарский базовый) язык».

**Структура и содержание работы:**

Работа проводится в форме диктанта, с грамматическим заданием. Диктант представляет собой связный текст, тематика которого соответствует возрасту учащихся 11 класса. Лексическое наполнение текста не превышает уровень актуального словарного запаса обучающихся 11 класса. Орфограммы, встречающиеся в тексте, определяются программой по родному (татарскому) языку 11 класса.

**Кодификатор проверяемых элементов содержания (предметные результаты):**

**1.1.Орфография как раздел лингвистики:**

- Обозначение на письме звука [W] буквой в начале слога буквам у, ү в конце.
- использование буквы й в начале слова и перед буквами о и ө (йөрәк, йозак)
- правописание букв о и ө.
- использование буквы һ и х в заимствованных словах
- правописание сдвоенных букв:
- правописание аффиксов -да/-дә, -та/-тә
- правописание частиц да/дә, та/тә;
- правописание союзов да/дә, та/тә.
- правописание мягкого знака (ь):
- правописание твердого знака (ъ)
- правописание частиц -мы/-ме, -дыр, -дер, -тыр, -тер, гына/генә, кына/кенә
- чередование букв п/б и к/г

**1.2.Пунктуация как раздел лингвистики:**

- Тире между подлежащим и сказуемым
- Знаки препинания при однородных членах
- Знаки препинания на конце предложения
- Знаки препинания при прямой речи и диалогах, обращениях
- Знаки препинания в ПП и СП
- Знаки препинания в простом осложненном предложении
- Знаки препинания при причастном и деепричастном оборотах
- Знаки препинания при обособленных и уточняющих членах предложения
- Тире в неполном предложении
- Знаки препинания при однородных членах с обобщающими словами
- Знаки препинания при словах и конструкциях, грамматически не связанных с членами предложения.
- Знаки препинания при сравнительных оборотах и конструкциях с союзом как
- Знаки препинания при вводных словах, вводных и вставных предложениях, словах-предложениях ДА, НЕТ, междометиях.

**Система оценивания работы:**
**<u>За работу выставляется 2 отметки:</u>**
**За диктант** выставляется одна отметка согласно нормам оценивания результатов обучения обучающихся 8 класов (нормы оценивания контрольного диктанта)

| 5 | 4 | 3 | 2 |
|---|---|---|---|
| 1 негрубая орфографическая + 1 негрубая пунктуационная | 2 орфографические + 2 пунктуационне; 1 орфографическая + 3 пунктуационные; 0 орфографических + 4 пунктуационные | 4 рфографические + 4 пунктуационные; 3 орфографические + 5 пунктуационные; 0 орфографические + 7 пунктуационные; 6 рфографические + 6 пунктуационные (если есть однотипные и негрубые орф. и пунк. ошибки) | 7орфографических + 7 пунктуационных; 6 орфографических + 8 пунктуационных; 5орфографические + 9 пунктуационные; 8орфографические + 6 пунктуационные |

**За грамматическое задание** выставляется одна отметка согласно нормам оценивания:
**«5»** – ставится за безошибочное выполнение всех заданий, когда ученик обнаруживает осознанное усвоение определений, правил и умение самостоятельно применять знания при выполнении работы;
**«4» -** ставится, если ученик обнаруживает осознанное усвоение правил, умеет применять свои знания в ходе разбора слов и предложений и правильно выполнил не менее 3/4 заданий;
**«3»** – ставится, если ученик обнаруживает усвоение определённой части из изученного материала, в работе правильно выполнил не менее 1/2 заданий;
**«2»** – ставится, если ученик обнаруживает плохое знание учебного материала, не справляется с большинством грамматических заданий;
**«1»** – ставится, если ученик не смог правильно выполнить ни одного задания.
Количество баллов не должно превышать максимального;
если анализ сделан верно, «5» баллов.

Предметные и метапредметные результаты оцениваются одной единой отметкой

ДЕМОВАРИАНТ.

**Сәламәтлек чишмәсе.**

**Һәркемгә билгеле: сәламәтлек – тормышның яме, чибәрлекнең нигезе.** Кеше өчен иң кадерле, мөһим нәрсә – сәламәтлек, шуңа күрә һәркем аны сакларга, ныгытырга тырыша.

Физкультура һәм спорт белән дәвамлы шөгыльләнергә кирәк, чөнки ул - сәламәт тәнле, саф акыллы булу өчен төп шарт.

Физкультура һәм спорт ни сәбәптән шундый тылсымлы көчкә ия соң? 5)**Моның сере шунда: физик күнегүләр кешенең тәнен чыныктыра, сәламәтлеген ныгыта.** Даими рәвештә физик күнегүләр ясарга гадәтләнгән кешенең кан йөреше җиңеләя, шуның аркасында кеше җитез һәм җиңел хәрәкәтле була. Өстәвенә сулыш киңәя - үпкә эшчәнлеге яхшыра. Физкультура һәм спорт кешенең сәламәтлеген саклауда, аны физик чыныктыруда менә шундый әһәмиятле урын тота, шуңа күрә аны сәламәтлек чишмәсе дип атыйлар. (Ш. Сайкин) (105 сүз)

**Грамматичесое задание:**

1 вариант.

1 нче җөмләдә иярчен җөмләнең мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләргә.

2 вариант.

5 нче җөмләдә иярчен җөмләнең мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләргә

**Ключи к грамматическим заданиям.**

**Сәламәтлек чишмәсе.**

1вариант. Һәркемгә билгеле:сәламәтлек ─ тормышның яме, чибәрлекнең нигезе.

нәрсә?

[▼]:( )─ иярченле кушма җөмлә,аналитик иярчен ия җөмлә.

2 вариант. Моның сере шунда:физик күнегүләр кешенең тәнен чыныктыра, сәламәтлеген ныгыта.

ул нәрсәдә?

[… шунда]: ( )─ иярченле кушма җөмлә, аналитик иярчен хәбәр җөмлә.

**1 вариант**

**Көнбагыш дус.**

Кәрим сизенә килде: кояш белән көнбагыш арасында ниндидер уртаклык, яшерен бәйләнеш бар, чөнки бакчадагы дусты кояш әйләнеше уңаена көнозын талгын гына борыла икән бит. **Кояш иртән кай яктан чыкса, көнбагыш шул якка караган була.** Кичләрен чуклы–чуклы башын кояш баешы ягына бора. Көнбагышның җанлы икәнлегенә ышанды Кәрим, шуңа күрә ул аны иң якын дусты итеп таныды. **Сентябрь җиткәч, беренче сыйныфка укырга барачагы хакында озаклап сөйләде.** Дусты аны бирелеп тыңлады. Көнбагышның дәү-дәү яфраклары кулларына орынганда, Кәрим сәер пышылдау ишетә: син тиздән мәктәпкә барасың, зур үсәсең.

Өлкәннәргә серләреңне сөйләсәң дә, алар сине күп вакыт аңлап бетермиләр. Кәрим шуңа төшенде: сөйләшер, серләшер өчен, көнбагыштан да яхшы һәм ышанычлы иптәш юк, чөнки ул алдашмый, үртәшми, кояшка һәм синең күзеңә карап тора. Кәримнең кайчак озын буйлы көнбагышка әвереләсе, аның кебек кояш уңаена талгын гына борыласы килә. Әмма тылсымлы әверелеш ясарга кулыннан килми шул аның. (Р.Низамиев) ( 138 сүз)

**Грамматическое задание:**

1 вариант.

2 нче җөмләдә иярчен җөмләнең мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләргә.

2 вариант.

5 нче җөмләдә иярчен җөмләнең мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләргә

**2 вариант**

**Туган як.**

Һәр кош үзенең туган ягын мактап сайраган кебек, минем дә туган ягымны мактыйсым, аның гүзәл табигатен тасвирлыйсым килә. Мин туган ягымның көмеш сулы елгаларын, зәңгәр күген, кояшлы таңнарын яратам. Челтерәп аккан чишмә сулары авыруларга шифа була, тәнгә көч бирә.

Ә туган ягымның таулары нинди! Мин кыш көне таудан чаңгы шуам. Тау битләре ни өчен яргаланган дисезме? **Кыш көне суыктан җир ярыла, ә яз көне аларга кар сулары кереп тула да ермаклар тагын да зурая.** Җир катламнарын күрәсең килсә, бер дә казып торасы юк, киләсең дә карыйсың.

Ә менә сезнең шушы кечкенә таучык артыннан кып-кызыл булып тәгәрәп чыккан кояшны күргәнегез бармы? Их, нинди матур ул күренеш! Бигрәк тә аның алтынсу-кызыл нурларының уйнавын карап тору күңелле. Аз гына җил исеп агач башларын селкеттеме,

су өстендә дулкыннар йөгерешеп, кояш нурларында ялтырыйлар. Әйтерсең лә Идел өстенә энже сипкәннәр. **Ә җил исмәгәндә, кояш Идел өстендә тагын үзенең йөзен күрә.** *(144 сүз.) (Матбугат битләреннән)*

**Грамматическое задание:**

1 вариант.

7 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләргә.

2 вариант.

14 нче җөмләдә иярчен җөмләнең мәгънә һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләргә

**Ключи к грамматическим заданиям.**

**1 вариант**

**Көнбагыш дус.**

1вариант. 2)Кояш иртән кай яктан чыкса, көнбагыш шул якка караган була.
(-са ), [ ] ─ иярченле кушма җөмлә,синтетик иярчен шарт җөмлә.

2 вариант. 5)Сентябрь җиткәч, беренче сыйныфка укырга барачагы хакында озаклап сөйләде.
(-кәч ), [ ] ─ иярченле кушма җөмлә,синтетик иярчен вакыт җөмлә.

**2 вариант**

**Туган як**

1вариант. 7) Кыш көне суыктан җир ярыла, ә яз көне аларга кар сулары кереп тула да ермаклар тагын да зурая.
[ ], ә [ ] да [ ] ─ теркәгечле тезмә кушма җөмлә.

2 вариант. 14) Ә җил исмәгәндә, кояш Идел өстендә тагын үзенең йөзен күрә.
(-гәндә), [ ] ─ иярченле кушма җөмлә,синтетик иярчен вакыт җөмлә.